# № 4 январь «Каракашлинская ООШ»

## *Алмаш №4 январь 2022 г.*
## *МБОУ «Каракашлинская ООШ»*



В этом выпуске:



20 января—85 лет Государственному советнику Республики Татарстан, Председателю Попечительского совета республиканского фонда «Возрож-дение», первому президенту Республики Татарстан Минтимеру Шариповичу Шаймиеву 1

4 января -75 лет народному поэту Татарстана, прозаику, драматургу, государственному деятелю, заслуженному работнику культуры ТАССР, РФ, лауреату Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая Татарстана Разилю Исмагиловичу Валееву 1

3 января – **75 лет** со дня рождения яркого и самобытного поэта, заслуженного деятеля искусств Татар-стана, лауреата Государственной премии им.Г.Тукая 1

**З ульфата(Дульфата Гусмановича Маликова)**

(1947-2007)



**Туган телдә жырлый чишмә,**
**Туган телдә шаулый таллар.**
**Туган телдә дәшсәм генә,**
**Туган жирем мине аңлар.**
**Рәзил Вәлиев**

***Минтимер Шәймиев:***

***«… Бер нәрсә бик мөһим: кеше яратмасаң, ихтыяр көчең булмаса, җитәкче булырга кирәкми. Әгәр очраклы кеше җитәкче була икән, ул үзен бәхетле сизә алмаячак..»***



**Тел ачылгач әйтә алсаң: "Әти!"- дип,**
**Күзләреңә яшьләр тыгылмас,**
**Туган телең әле бу булмас.**
**Соң минутта әйтә алсаң: "Әни!" - дип,**
**Соң минутта әйтә алсаң: "Әти!" - дип,**
**Күзләреңә яшьләр тыгылыр,**
**Туган телең әнә шул булыр.**

**Зөлфәт**

***Милләтебезне, телебезне саклау, аны үстерү, халкыбызның үзаңын киләчәктә дә югарыга үрләтү - ул без башкарырга тиешле гамәлләр.***
***М.Ш.Шәймиев***

# Из жизни школы

Плох тот народ, который не помнит, не ценит и не любит своей истории» (В.М.Васнецов)

## Зимние каникулы...

**В дни зимних каникул с учащимися 5-6 классов была организована игра «Поле чудес» Победителем стал ильназ Садыков. Все участники и болельщики были очень активны.**



## Помощь ветерану



**Юнармейцы поздравили ветерана тыла и педагогического труда Гайсина А.Г. С Новым Годом и с днем рождения. Ребята вооружились лопатами и убрали скопившийся снег во дворе, расчистили дорожки от**



## Шәхесләребез



**Кәрәкәшле туган як тарихын өйрәнү музеенда авылның юбилеена багышланган «Шәхесләребез» дип исемләнгән күргәзмә кысаларында авылдашыбыз. РСФСР-ның атказанган мәдәният хезмәткәре Гараф Шәрәфетдиновка багышланган күргәзмә-лекцияләр оештырылды.**

**Укучылар Гараф аганың тормыш һәм иҗат юлы, шәхси язмалары, мәкаләләре белән таныштылар. Аның күренекле шәхесләр белән язышкан хатлары да музейда саклана. Шагыйрь Сибгать Хәким язган хат укучыларда аеруча зур кызыксыну уятты. Анда авылыбызның чишмәләре турында бик матур истәлек бирелгән. Әдәбият кабинетында да Гараф абый бүләк иткән китаплар саклана.**





**Отряд «Юнармия» присоединилась к Акции памяти «Блокадный хлеб», цель которой - напоминание о мужестве и стойкости мирных жителей Ленинграда в годы Великой Отечественной войны.**

**Молодое поколение увидело норму суточного хлебного пайка, был представлен кусочек хлеба в 125 граммов, который помещается на ладони.**

## Утренняя гимнастика



**Отряд «Юнармия» организовала утреннюю гимнастику с учащимися начальных и 5-9 классов.**



# Туган телем- иркә гөлем

## РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛАГА

## 60 ЯШЬ



**Шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган сәнгать әһеле, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Язучылар берлеге рәисе Ркаил Рафаил улы Зәйдуллага (Зәйдуллин) 60 яшь**

### СЕЗНЕКЕМЕ?

**Нәрсә житми?**
**Ник сулкылдый күңел?**
**Үкчәсенә баса-баса моңнын,**
**Берьялгызым менә төннәр буе**
**Урамында йөрим авылымның.**

**Бабаларым!**
**Шул ук җегәр миндә,**
**Шул ук иман яши йөрәгемдә!**
**…….**
**Мин дә туңам - сез өшисез икән,**
**Сезгә эссе икән - мин дә янам!**
**«...Саумысез!» - дип дәшәм туган телдә,**
**Туган телдә - димәк, сезнең дәвам.**

**Иманым нык, шул ук сезнең иман!**
**Таңнарыма чыгам, кичеп төнне.**
**...Нигә һаман тыныч түгел күңел:**
**Сезнең дәваммы мин, сезнекеме?**

-

Шагыйрь, прозаик, драматург һәм публицист Ркаил Зәйдулла (Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин) 1962 елның 23 гыйнварында хәзерге Чуашстан Республикасының Комсомол районы Чичкан авылында укытучы гаиләсендә туа. Башлангыч мәктәпне – туган авылында, урта мәктәпне күршедәге Чурачык авылында тәмамлаганнан соң, 1979 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга килә. Университетның соңгы курсларында укыган чакта ук республика яшьләр газетасы («Татарстан яшьләре») белән хезмәттәшлек итә башлый. 1985 - 1989 елларда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында эшли.1989 елда яшьләр өчен «Идел» журналы ачылгач, Ркаил Зәйдулла шул журналның бүлек мөхәррире була.

Р.Зәйдулла –үткен каләмле, туры сүзле публицист. Татар милләтенең тарихи язмышы һәм бүгенге хәле, дин, тел, мәдәният һәм милләт алдына килеп баскан башка бик күп төрле мәсьәләләр аның һәрвакыт игътибарын үзенә җәлеп итә, ул аларның берсенә дә битараф түгел, мөмкинлеге булган саен аларга матбугат аша үзенең мөнәсәбәтен белдерә бара.

2020 елда Татарстан Дәүләт Советы депутаты, 2021 елда- Татарстан Язучылар берлеге рәисе   итеп сайланды.

### ИКМӘК

**Татлы тәм бар ипекәйдә.**
**Төшендем мин яши-яши:**
**Кеше аңа үз өендә**
**Сөенечен кушып ашый.**

**Ачы тәм бар ипекәйдә.**
**Карусыз гомер юлдашы:**
**Шуның өчен аңа кеше**
**Көенечен кушып ашый.**

**Бер тәм калмый ипекәйдә.**
**Язмышында – соңгы ашың:**
**Ул сиңа күчәнә тып-тын,**
**Син җир белән кавышасың.**

### ЫШАНЫЧ

**Томалаган кара болыт…**
**Сиздерми һәм бик сак кына**
**Кояш үтеп керә барыбер**
**Туган җирнең туфрагына.**

**Элекке бабайлар сыман**
**Җиргә куеп колагыңны,**
**Ишетәсеңме, җылы иснәп,**
**Бөҗәкләрнең елаганын?**

**Анда гел кысыр хәрәкәт, –**
**Шулмы күңелне җилкетә?**
**Ә өстән энә карагы,**
**Кигәвеннәр очып үтә.**

**Таралыр ул кара болыт!**
**Кояш чыгар, һәм челтерәп**
**Ләйсән явар сөенеч булып,**
**Фәкать ышанырга кирәк.**

**Гөл ачылыр, су яктырыр,**
**Гел яңача балкыр төсләр.**
**Яфрак астына күченер**
**Мең кузле бу үрмәкүчләр.**

**Ләкин бүген хәлләр хәтәр,**
**Күренми бер терәге дә…**
**Таянасы калды бары**
**Һәркемгә үз йөрәгенә.**

## Күңелле тәнәфес

**1. Борынгы заман сәгате.**

**2. Уйларны еракка тапшыру җайланмасы.**

**3. Нинди җәнлек исеменең беренче хәрефен “у”га алыштыруга еланга әйләнә?**

**4. Нәрсәне йомык күз белән дә күреп була?**

**5. Кара мәче нинди ишектән керә?**

**6. Нинди сорауга бервакытта да “Әйе” дип җавап биреп булмый?**

**7. Ашлыкны ни өчен чәчәләр?**

**8. Нинди сәгать тәүлеккә ике мәртәбә генә вакытны дөрес күрсәтә?**

**9. Тугай кайчан сайрый?**

**10. Өстәл янында бигрәк тә нәрсә кирәк?**

**11. Табышмак сүзен ничек укырга кирәк?**

**12. Өчәү өчәү өч төштә,**
**Берәү генә бер төштә.**

**13. Кайсы җирдә шәһәрләрдә өйләр, елгада сулар, урманнарда агач булмый?**

**14. Атнадагы 5 көннен исемнәрен әйтмичә генә саный аласыңмы?**

**15. Кем өйдән биегрәк сикерә ала?**

**16. Кем алдында барысы да баш киемен сала?**

**17. Нинди савыттан ашап булмый?**

**Урыс теле дәресе:**
**- Рустам, телефон звОнит или звонИт?**
**- Белмим, апа, у меня шалтрата.**

***

**Улым, имтиханыңныны ничә-легә бирдең?**
**- Икелегә, эти.**
**- Егет икәнсең!**
**- Ник?**
**- Авылда да эшләргә кеше кирәк.**




**Айрат мәктәптән кайтып кергәч:**
**- Җитте! Бүтәнчә мәктәпкә аяк та атламыйм!**
**- Нишләп?**
**- Укый белмим, яза белмим, сөйләшеп утырырга да ярамый!**

***

**Сез скрипкада уйный беләсезме?**
**- Төгәл генә әйтә алмыйм... Бер дә уйнап караганым юк.**

**Адрес:**
**РТ, Ютазинский район, с. Каракашлы, ул. С. Батыршина, д.36**

**Электронная почта:**
***karakasschol @*** **mail.ru**

**Укытучы:**
**– Балалар, Африкада яшәүче биш хайванны атагыз әле?**
**Марат:**
**– Ике зебра, өч жираф.**

**Әтисе улына:**
**– Кем конфетларны ашап бетерде?**
**– Мин түгел!**
**– Тагын кирәкме соң?**
**– Әйе.**
**күлмәкләрем пычыранса – юасың, тамагым ачса – ашатасың. Мин булмасам, нишләр идең микән**

Редколлегия:
Редактор: **Латыйпов Раил.**
Секретарь: **Хамитов Илһам**

**Ибраһимов Динар**

**Миннушин Рәнис**

**Латыйпов Ринас**